РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

08.12.2021 | № 1400-п

Дини оешмаларның Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль милкендәге дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турындагы гаризаларын караганда туган мәсьәләләр буенча комиссия төзү турында

“Дәүләт һәм муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру турында” 2010 елның 30 декабрендәге 327 номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Дини оешмаларның Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль милкендәге дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турындагы гаризаларын караганда туган мәсьәләләр буенча комиссия төзергә.
2. Дини оешмаларның Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль милкендәге дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турындагы гаризаларын караганда туган мәсьәләләр буенча комиссия төзү турында Нигезләмәне расларга.
3. Дини оешмаларның Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль милкендәге дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турындагы гаризаларын караганда туган мәсьәләләр буенча төзелгән комиссия составын расларга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты аппараты Җитәкчесе М.Р. Кәримовка йөкләргә.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 8 декабрендәге 1400-п номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Дини оешмаларның Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль милкендәге дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турындагы гаризаларын караганда туган мәсьәләләр буенча комиссия төзү турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә дини оешмаларның Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль милкендәге дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турындагы гаризасын (алга таба комиссия) караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия төзү һәм аның эшчәнлеге тәртибен билгели.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм күрсәтмәләре, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләре, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм күрсәтмәләре, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары, шулай ук әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

1.3. 1.3.Комиссия үз компетенциясе нигезендә кабул иткән карарлар вәкаләтле орган тарафыннан Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру турында карарлар кабул итү өчен нигез була.

2.Комиссиянең төп бурычлары

2.1. Дини оешмаларның Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль милкендәге дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турындагы гаризаларын караганда барлыкка килә торган каршылыкларны җайга салу.

2.2. Дини оешмага дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында карар кабул итүгә яки вәкаләтле органның дини оешма гаризасын карау белән бәйле гамәл кылуына (гамәл кылмавы) бәйле рәвештә физик һәм юридик затларның хокукларын һәм (яки) законлы мәнфәгатьләрен бозулары турында физик һәм юридик затларның гаризаларын карау.

3. Комиссиянең төп функцияләре

3.1. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә:

3.1.1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле мәгълүматны соратып ала.

3.1.2. Үз утырышларында комиссия компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары, дин белеме, культурология, хокук һәм башка өлкәләрдәге оешмалар һәм белгечләр вәкилләрен тыңлый.

3.1.3. Үз компетенциясе чикләрендә вәкаләтле органга дини оешмаларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль милкендәге дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру яисә дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшырудан баш тарту турында тәкъдим белән нигезләнгән карар кабул итә.

4.Комиссиянең хокуклары

4.1. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

4.1.1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкилләрен, оешмаларны һәм дин белеме, культурология, хокук һәм башка өлкәләрдәге белгечләрне
комиссия эшендә катнашу өчен җәлеп итәргә.

4.1.2. Комиссия компетенциясенә керә торган мәсьәләләрне карау өчен эш төркемнәре төзергә.

5.Комиссия эшчәнлеге тәртибе

5.1. Комиссия составы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе карары белән раслана.

5.2. Комиссия составына комиссия рәисе һәм комиссия әгъзалары керә.

5.3. Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итүне комиссия рәисе башкара.

5.4. Комиссия утырышларын әлеге Нигезләмә нигезендә комиссия карарын таләп итә торган мәсьәләләр барлыкка килгән саен үткәрергә. Комиссия рәисе карары буенча комиссия күчмә утырышлары уздырыла.

5.5. Комиссия утырышларын оештыру, үткәрү һәм ул кабул иткән карарларның үтәлешен тикшереп тору комиссия рәисенә йөкләнә. Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия әгъзасы утырышта катнашмаса, карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы.

5.6. Комиссия карары комиссия утырышында катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм утырыш беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, утырыш рәисе тарафыннан имзалана.
Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора. Кабул ителгән карар белән килешмәгән комиссия әгъзаларының аерым фикере комиссия карарына кушымта рәвешендә рәсмиләштерелә.

5.7. Комиссия карары, шулай ук әлеге карар белән килешмәгән комиссия әгъзаларының аерым фикере 7 көн дәвамында вәкаләтле органга җибәрелә.

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2021 елның
8 декабрендәге 1400-п номерлы
карары белән
РАСЛАНГАН

**Дини оешмаларның Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль милкендәге дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турындагы гаризаларын караганда туган мәсьәләләр буенча төзелгән комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Кәримов М.Р. | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты аппараты Җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Галиуллин А.М. | Саба муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе, комиссия рәисе урынбасары; |
| Вәгыйзов Н.Н. | Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының баш белгече, комиссия секретаре; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Миникаев А.И. | Саба муниципаль районы Советының юридик бүлеге начальнигы (килешү буенча); |
| Рамазанов Э.Д. | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы; |
| Авыл җирлеге (шәһәр җирлеге) башлыгы - объектның урнашкан урыны буенча (килешү буенча). | |